Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Уракчы авыл җирлеге Советы

**КАРАР № 11**

Уракчы авылы 2017 елның 22 августы

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уракчы авыл җирлеге Советының 2014 елның 7 октябрендәге “Җир салымы турында” 14 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 5 маддәсенең 4 өлеше, 31 бүлеге (икенче өлеш), «Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешенә үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 29 декабрендәге 396-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 35 маддәсендәге 10 өлешенең 3 пункты, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уракчы авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уракчы авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уракчы

авыл җирлеге Советының 2014 елның 7 октябрендәге “Җир салымы турында” 14 номерлы” карарына (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уракчы авыл җирлеге Советының 10.11.2014 ел, № 10, 22.05.2015ел, №11.\1 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән ) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 пунктны түбәндәгечә үзгәртергә:

«5. Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге нигезендә салым базасын киметү хокукын раслаучы документлар салым түләүчеләр тарафыннан үз теләге белән салым органына тапшырыла».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль

районы Уракчы авыл  җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Уракчы авылы, Совет урамы, 36Айорт; Мельничный Пүчинкәсе авылы, Киров урамы, 20Б  йорт адреслары буенча урнашкан  махсус мәгълүмат стендларында һәм  Татарстан Республикасы Балык  Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2016

елның 1 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне  үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы

Балык Бистәсе  муниципаль районы
Уракчы авыл җирлеге Башлыгы                                    Ф.М.